Г. Тамендаров
Р. Гузаиров




# ХАЛЫК МОҢНАРЫ



Галимжан Тамендаров

# Гармун халык моңнары

3 – издание

Алматы–2017

Мөхәррирләре – **Рәвил Гөзәиров, Сұлтан Қалиұлы**.

**Тамендаров Галимҗан Гәрәй улы**
**Рәвил Гөзәиров Якуб улы**
“ГАРМУН ХАЛЫК МОҢНАРЫ”

Әлеге китапта тугандаш Казагыстан Республикасының Алматы каласында яшәүче танылган композитор – Галимҗан Тамендаровның, билгеле шагыйрьләр Рәвил Гөзәировнвң, Гриф Хәйруллинның (Тимер Захитның), билгеле казах язучыларының сүзләренә иҗат ителгән җырлары, инструменталь әсәрләре тупланган.

Аранжировка Колесниковой Ирины Евгеньевны.

Слова написаны на мелодию.



Тамендаров Галимжан Геряевич
14.06.1947г.

Более 50-летним педагогическим стажем и 30-летней композиторской деятельностью. За эти годы он воспитал более 60000 учащихся, многие из которых в дальнейшем стали знаменитыми артистами, музыкантами, кинорежиссерами, врачами, строителями, аграрниками, финансистами, бизнесменами и парламентариями. Всех их объединила «Песня». Автор более 200 песен и инструментальной музыки. Серебряный призер фестиваля всемирной универсиады 1973 года, Москва. Лауреат международных конкурсов и фестивалей. Отличник просвещения КазССР. Заслуженный работник образования Республики Казахстан, заслуженный работник культуры Республики Татарстан. Награжден медалью Президентом Российской Федерации в честь 1000-летия г.Казани и медалью ветерана труда. Член союза композитора Республики Казахстан. Руководитель татарского народного ансамбля «Сарман» - «Бул-бул».



Гузаиров Равиль Якубович
26.09.1942г.


Один из создателей и художественный руководитель татарского народного ансамбля «Сарман». Лауреат международных конкурсов и фестивалей. Автор слов более ста песен, половина из них написана на музыку, что является особым талантом поэта. Заслуженный работник культуры Республики Татарстан. Поэт-песенник. Награжден медалью в честь 70-летия Союза писателей Республики Татарстан. Обладатель грампластинок с исполнением татарских народных песен фирмы «Мелодия», 1987г.

Читтә яшәүчегә читен,
Ярый әле, җыр-моң бар...
Шуны җанга җиткерәләр
Көмеш телле гармуннар!...

**Рәвил Гөзәиров**

# АШКЫНАМ МИН ТУГАН ЯГЫМА

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Ничә айлар, ничә еллар
Акшынам туган илгә.
Белмим, нигә язмышларым
Кайтармый туган җиргә.

Кайтсам иде үз ягыма
Алсу таңнар атканда.
Кошлар моңын тыңлар идем
Тугай буйлап кайтканда.

Ялан-аяк йөрер идем
Чирәмгә чык төшкәндә.
Йөрәкләрем янмас иде
Салкын суын эчкәндә.

Кошлар да бит җылы яктан
Әйләнеп кире кайта.
Кошлар булып, канат кагып
Кайтыйк без туган якка.



# ИСТАМБУЛ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Гөл-бакчаларга күмелгән
Гүзәл шәһәр Истамбул.
Азан моңына моңайган
Изге шәһәр Истамбул.

К у ш ы м т а:
Истамбул, Истамбул,
Манаралы Истамбул.
Истамбул, Истамбул,
Алтын айлы Истамбул.

Алтын айлы манаралар
Өмет бирәләр безгә.
Саф йөрәктән, чын күңелдән
Бәхет телибез сезгә.


К у ш ы м т а.

Безнең ата-бабалар да,
Истамбулга килгәннәр.
Азан әйтеп, намаз укып,
Чын мөселман булганнар.

К у ш ы м т а.

# ҮЛЕМСЕЗЛЕК

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**





Айлар үтте, еллар үтте,
Ак чәчәкләр сине көтте.
Күпме сулар акты,
Алсу таңнар атты,
Ромашкалар чәчәк атты.

Көтте сине сайрар кошлар,
Сандугачлар һәм былбыллар.
Кайталмадың, калдың –
Еракларда мәңге,
Алманнарга баш имичә.

Сүнмәс җырың синең калды
Йөрәкләрдә урын алды.
Батырлыгың белән
Матур исемең калды,
Үлемсезлек яулап алды!

## ТУЙ ҖЫРЫ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Якты йолдызлар балкытты
Туган якларның күген.
Чәчләрен – чәчкә бәйләде,
Ике яшь йөрәк бүген.

К у ш ы м т а:

Туй, туй, бүген туй.
Бергә булсын уйлары,
Сылу икән буйлары,
Котлы бүлсын туйлары!!

Җырлый, җырлый суга бара
Яшь килен урам буйлап.
Әби-бабайлар уфтана,
Узган гомерен уйлап.

К у ш ы м т а.

Пар күгәрчен кебек гөрләп
Оялар сез корыгыз.
Мәхәббәтне югалтмыйча
Тигезлектә торыгыз!!

К у ш ы м т а.

Бала-чага тавышына
Тулсын өегез эче.
Елдан елга сүрелмәсен
Саф мәхәббәтнең көче.

К у ш ы м т а.

# ТАМАШАЧЫ ДУСЛАРЫМА

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Концертлардан концертларга
Сезне уйлап шундый сагынам.
Зинһар өчен килегез дип,
Чын күңелдән сезгә ялынам.

Кушымта:
Сезнең матур йөзләрегез,
Шаян-серле күзләрегез,
Иркәлиләр һәм назлыйлар
Шундый матур сүзләрегез.

Чакырамын сезне, дуслар,
Уйнап, көлеп күңел ачарга.
Авырлыклар килгәндә дә,
Сер бермичә генә яшәргә.

Кушымта.

Бирер идем жәлләмичә
Йөрәгемнең кайнар хисләрен,
Бакчаларда гөрләп үскән
Сирень чәчкәсенең исләрен.


Кушымта.

Яшәсәгез, мин дә яшим,
Сездән бетмәс көчләр алып.
Ярсып типкән йөрәгемнең
Ялкынында дөрләп янып.

Кушымта.

# СИН БИТ МИНЕМ БЕР ГЕНӘМ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Гомерлеккә сөйдем сине,
Син бит минем бер генәм.
Ямьләндердең тормышымны,
Матурым син, гөл генәм.

Хәйран калам кайбер вакыт,
Синең сабырлыгыңа,
Ничә еллар бирешмисең,
Тормыш авырлыгына.

Яннарымда син булганга
Яшимен мин куанып.
Нурлы йөзләреңә карап,
Бала кебек юанып.

# БЕР ЯШЬЛЕКТӘ, БЕР КАРТЛЫКТА

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**





Уңган була, матур була
Безнең якның кызлары.
Алматының алмасыдай
Балкып тора йөзләре.

Вак-вак атлап, йомшак басып
Бииләр безнең кызлар.
Күңел хисләрен яңартып
Килсеннәр матур язлар.

Кайда гына йөрсәм дә,
Уйларымда син генә.
Бер яшьлектә, бер картлыкта
Уйнап көлгән без генә.

# ҖИЛЛӘР ИСӘ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Җилфер-җилфер җилләр исә
Безнең туган якларда.
Сагыну утларында янам
Сез булмаган чакларда.

Уйнап, көлеп күңел ача
Безнең авыл яшьләре.
Эштә уңган, җырда булган,
Бигрәк матур үзләре.

Әле дә булса күз алдымда
Басулары-кырлары.
Еракларга киң таралган
Безнең халык җырлары.

Зәңгәр күктән очкан кошлар
Канатлары талмасын.
Яшьли сөю хисләребез
Үкенечкә калмасын.

## НАКИЯ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Безнең җырчы Накия
Алтын балдагын кия.
Яннарымнан үтеп китсә,
Йөрәгем янып-көя.

Ялтыр-йолтыр килә күзе,
Елмаеп тора үзе.
Йөрәгемә утлар яга
Һәрбер сөйләгән сүзе.

Моңлы аның тавышлары,
Халык аны ярата.
Кыйгач кашларын уйнатып,
Ул үзенә карата.


Яшәү көче балкып тора,
Күзләре янып тора.
Күңеленең җылылыгы
Үзенә тартып тора.

Төшләремдә шул Накия
Битемнән килеп сөя.
Көне-төне шуны уйлап,
Йөрәгем янып-көя.



# КОТЛЫ БУЛСЫН САБАНТУЙ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Кыз: Яктырып янсын йолдызлар
Алматының күгендә!
Тырыш хезмәт, саф мәхәббәт
Булсын безнең күңелдә.
Егет: Җәйнең матур көннәрендә
Килде безгә ямьле туй.
Дуслаштырып бар халыкны
Котлы булсын сабантуй!

Кушымта.
Әйе шул, шулай шул,
Бүген бәйрәм, бүген туй!
Әйе шул, шулай шул,
Бездә бүген сабантуй!

Кыз: Яңгырасын сабантуйда
Тальян гармун телләре,
Башкортымның курайлары,
Моңлы казак көйләре!

Егет: Биесәк тә, җырласак та,
Килешеп тора безгә.
Сабантуйдан сабый туйлар
Күбәйсен иде көзгә.

Кушымта.

Кыз: Уртага чык, батыр егет,
Күрсәт батырлыгыңны!
Япь-яшь кызлар гашыйк булсын
Күреп матурлыгыңны.

Егет: Хезмәттә дә, сәнгатьтә дә
Алдынгы безнең яшьләр.
Сабантуйларда җиңәрлек
Бар әле бездә көчләр.

Кушымта.


Кыз: Сабантуйларны үткәрик
Дуслыкта, бердәмлектә.

Егет: Тугандашлар һәм кардәшләр
Яшәсен күркәмлектә!

Кушымта.

# БЕЗГӘ КИЛДЕ КЫШ БАБАЙ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Җырлый-җырлый, бии-бии
Яңа елны каршылыйк.
 Кушымта:
Тыпырдатып басаек,
Бердәм кулны чабаек.

Кыш бабай безгә килде,
Матур бүләген бирде.
 Кушымта.

Әй, балалар, торыгыз,
Якты булсын юлыгыз.

 Кушымта.

Әйлән-бәйлән уйнагыз,
Җырлап биеп туймагыз.

 Кушымта.

Кыш бабай биеп китте,
Яңа ел килеп җитте.

 Кушымта.

# НУРИЯ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Нечкә билле Нуриякәй
Матур күлмәген кия.
Шул Нурия дия-дия,
Егетләр янып-көя.

Йөзләрендә нурлар уйный,
Кыйгач кашлары кара.
Тал чыбыктай нечкә билле
Нурия суга бара.

Нурлы назлы Нуриякәй
Ап-ак калфагын кия.
Барган чакта чишмәләргә
Чәчәкләр башын ия.


Алсу таңнар аткан чакта
Егетләр йоклап ята.
Көянтәләрен уйнатып
Нурия судан кайта.

Нечкә билле Нуриякәй
Матур көлмәген кия.
Шул Нурия дия-дия,
Егетләр янып-көя.



# ӘЙ, ГАРМУН ТЕЛЛӘРЕ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Тальян гармунның моңнары
Өздерә үзәкләрне.
Ярсу еллар, ташкын сулар
Ярсыта йөрәкләрне.

Кушымта:
Әй, гармун телләре,
Сагынган гармунчыны.
Бармакларын талдырмыйча
Гармунда уйнаучыны.

Әйтерсең дә, барлык хисләр
Гармунның күрегендә.
Әле дә булса сүрелмәгән
Һәркемнең күңелендә.

Кушымта.

Гармун бит ул бар халыкның
Көйләрен җыйнаучысы.
Нигә моңаймасын гармун,
Моңайса уйнаучысы.

Кушымта.

Гармунчының йөрәк серен
Гармун телләре сөйли.
Гашыйк итеп ул үзенә
Матур көйләрен көйли.

Кушымта.



# ЯШЬЛЕГЕМНЕҢ ТАҢНАРЫ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Сандугачларны уята
Яшьлегемнең таңнары.
Сүнгән утларны яндыра
Тальян гармун моңнары.

К у ш ы м т а:
Хыялларым канатланып
Яшьлеккә алып китә.
Әкрен генә, сиздермича
Яшь гомеркәйләр үтә.

Алсу таңнарны аттыра
Сандугачкаем сайрап.
Канатларыңны талдырма
Кунар талыңны сайлап.


К у ш ы м т а.

Биек тауларның башында
Каеннар яфраксыз.
Бу дөньяда кошлар гына
Кайгысыз, хәсрәтсез.

К у ш ы м т а.

# САЛКЫН ЧИШМӘ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Салкын чишмә буенда
Күгәрченнәр гөрләшә.
Бөдрә таллар шыбырлашып,
Чишмә белән серләшә.

Чылтыр-чылтыр ага су,
Тирә якка ямь биреп.
Сусап суын эчкәннәргә
Шифалы тәмнәр биреп.

Яшәртеп болыннарны,
Салкын чишмәләр ага.
Сандугачлар су эчкәндә
Канаткайларын кага.

Салкын чишмә, көмеш су,
Әйләнәсе тал-тирәк.
Мәхәббәтнең саф хисләрен
Саклый белергә кирәк.



# ҖИҢҮ КӨНЕ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Җиңүчеләр омтылдылар
Берлиндагы мәйданга.
Ташкын кебек көчне күреп,
Дошман калды хәйранга.

Кушымта:
Меңәрләгән катюшалар
Утлы юллар салдылар.
Җиңү көне бәйрәмнәре
Тарихларда калдылар.

Батырларның йөрәгендә
Нәфрәт уты кабынды.
Чит җирләрдә май аенда
Үз ягын ул сагынды.

Кушымта.

Жәлләмичә гомерләрен
Ватан өчен бирделәр.
Үлемсезлек яулар өчен
Рейхстагка килделәр.


Кушымта.

Җилфердәде кызыл байрак
Дошманны җиңдек диеп.
Батырларның кайнар каны
Байракта калды диеп.

Кушымта.

# МАМЛЮТЕМ КЫРЛАРЫНДА

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Туган ягым еракларда,
Ямьле Ишел ягында.
Ашкынам мин шул якларга
Сагындырган чагында.

Гөлбуки күл буйларында
Моңлы җырлар җырладым.
Төрле кошлар сайраганда
Хәйран калып тыңладым.


Печән чаптым, урман кистем
Мамлютем кырларында.
Йөрәгемә шифа таптым
Халкымның җырларында.

Йөри идем урамында
Ап-ак карлар яуганда,
Беренче рәт гашыйк булып
Утларында янганда.

Хәзер яшим еракларда
Шул көннәрне сагынып,
Төшләремдә кошлар булып
Ярсып канат кагынып.

# ЧАБАТА

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Аулакларда без биибез,
Көе килми димибез.
Бергә кайларга барсак та,
Аяктагы чабата.

Кушымта:
Чаба-чаба, чабата,
Биегәнне ярата.

Әткәем дә яшь чагында
Чабата киеп үскән.
Балачак сукмакларында
Эзен калдырып үткән.

Кушымта.

Чабата кисәк тә, дуслар,
Бай булсын безнең күңел.
Тормыш авырлыкларына
Бирешкәннәр без түгел.

Кушымта.

Сөям дигән сүзләреңне
Әллә ничә укыдым.
Сиңа бүләк итәр өчен
Мин чабата тукыдым.

Кушымта.

Чаба-чаба, чабата,
Биегәнне ярата.
Матур кызлар дәртле биеп
Үзләренә карата.

Кушымта.



# НАУРЫЗ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Авыллардан авылларга,
Шәһәрләрдән шәһәргә,
Тирә-якны ямьләндереп
Килде безгә Наурыз.

Кушымта:
Наурыз, Наурыз, Наурыз ай,
Дәстәрханың шундый бай!
Хәләл ризыклар биргән
Изге бәйрәм Наурыз ай!

Изге ниятләре белән
Безгә килде Наурыз.
Бар халыкны дуслаштырып
Бәхет бирде Наурыз.


Кушымта.

Чын күңелдән Наурызга
Озын гомер телибез.
Сәлам биреп барыгызга,
Исән-саулык телибез.

Кушымта.

## ӘТКӘЕМ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Балачактан өйрәттең син
Ат җигәргә, әткәем.
Салкын чишмә буйларында
Печән чаптык, әткәем.

Урманнарга бара идек,
Билгә балта кыстырып.
Моңлы итеп озын көйгә,
Җырлый идек сыздырып!

Колагымда һаман чыңлый,
Әткәемнең җырлары.
Шул моңнарны юксыналар
Авылымның кырлары.

Безнең өчен жәлләмәде
Гомерләрен әткәем.
Йөрәгемнең иң түрендә
Саклыйм сине, әткәем!



# Ә КАНАТСЫЗ МИҢА НИШЛӘРГӘ?

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Чит җирләрдә гомер уздырсам да,
Туган илем үзенә тарта.
Олыгайган саен йөрәгемдә
Сагыш тулы хисләрем арта!!

Туган якларыма чакыралар
Тезелешеп очкан кошлары.
Исләремә төшеп сагындыра
Үзәк өзгеч салкын кышлары.

Кангылдашып киткән кыр казлары
Ашыгалар җылы якларга.
Очып киткән кошлар кире кайта,
Ә канатсыз миңа нишләргә!!

# БЕЗНЕҢ ТУКАЙ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Тукай теле, ана теле,
Газиз халкымның теле.
Бар дөньяны ямьләндергән
Милли бакчамның гөле.

Безнең Тукай, бөек Тукай!
Авылда туып үскән.
Кара урманнар арасыннан
Адашмыйча ул үткән.

Аз яшәде безнең Тукай
Якты дөнья йөзендә.
Милләтемнең моң-зарлары
Мәңге үлмәс сүзендә!

Рәхмәт сиңа – бу дөньяга
Шагыйрь булып туганга!
Алсу таңнар аткан чакта
Нурларына тулганга.

Без Тукайны яратабыз,
Җырларын яңартабыз.
Моңлы, назлы җырын җырлап
Кайгыны таратабыз.

# ӘЙ СЫЛУ КЫЗ, СЫЛУ КЫЗ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Әй сылу кыз, сылу кыз!
Нигә бик шаяртасың?
Яшермичә генә әйт,
Кемне син яратасың.

Кушымта:
Гашыйк булдым үзеңә,
Серле зәңгәр күзеңә.
Йөрәгемне эреткән
Балдай татлы сүзеңә.

Гашыйк булып үзеңә,
Карыйм зәңгәр күзеңә.
Шул кадәрле тилмерәм
Сөям дигән сүзеңә.

Кушымта.

Көзгелергә карыйсың,
Чәчләреңне тарыйсың.
Күз сирпеп караганда,
Күңелемә ярыйсың.

Кушымта.

Күзләрең зәңгәр диңгез,
Йөгерек дулкыннары.
Үзенә мине тарта
Өермә упкыннары.
Кушымта.

## КОДА БЕЛӘН КОДАГЫЙ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Борынгылар әйткән икән:
“Кияү бала йөз еллык
Кодаларыбызда уңган,
Кодалар бит мең еллык”.

Кода белән кодагый
Бигерәк тә пар килгән,
Иң яраткан кызларын
Безнең егеткә биргән.


Тыпырдатып бии кода,
Башы әйләнмәс микән.
Шул кадәрле дәртле бии,
Оста биюче икән.

Кодагый да ис китәрлек,
Янып тора күзләре.
Кода янында әйләнә,
Пар килгәннәр үзләре.



# ЯР, ЯР!
## (Никах туенда җырлый торган җыр)

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Милләтемнең бер кызын,
“Рамиль” алды, яр, яр!
Сылулыгын күргәндә,
Таң калырсың, яр, яр.
Пар күгәрченнәр кебек,
Гөрләшегез, яр, яр!
Алсу таңнар атканчы,
Серләшегез, яр, яр!


Барча туган, дус-ишләр –
Бәхет тели, яр, яр!
Гыйшык утын сүндерми
Яшәгез сез, яр, яр!
Мәхәббәт ул бер генә –
Онытмагыз, яр, яр.
Бер-берегезне яратып,
Кушылдыгыз, яр, яр.

Мәхәббәт диңгезендә
Коеныгыз, яр, яр!
Яшәү матурлыгына
Сөенегез, яр, яр!
Көчле мәхәббәтегез
Җимеш бирсен, яр, яр!
Сезгә озын гомерләр
Ходай бирсен, яр, яр!



# АНА ТЕЛӘГЕ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Гөрләп чәчәк аткан яшьлек мәхәббәте
Бар дөньяны ямьләндереп җимеш бирде.
Яшәешне мин бит дәвам итәм диеп –
Изге җанлы сабый дөньяга килде.

Тәпи-тәпи йөреп китәрсең син бер көн.
Бар халыкның куанычы булырсың син.
Якты кояш нурларына тулырсың син.
Намуслы, ил баласы булырсың син!

Әткәм, әнкәм диеп сөйләп китәрсең син.
Күбәләкләр белән бергә уйнарсың син.
Мәктәпләргә барып, белем алырсың син
Яннарыма йөгереп килерсең син.

Канатларың үсеп җиткәч һәм ныгыгач,
Кошлар кебек биеклеккә син очарсың.
Зәңгәр күктә очкан батыр лачын булып –
Бар галәмне яратып син кочарсың.

Дан җырлыйк без мәңге сүнмәс мәхәббәткә,
Иман нурлы әтиләргә, әниләргә.
Ак яулыклы изге ңанлы әбиләргә.
Милләтемнең нык нигезе әби-бабайга!..

## БЕЗНЕҢ ЯКНЫҢ КЫЗЛАРЫ...

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Алматының алмасыдай
Безнең якның кызлары –
Нур чәчеп балкып торалар
Халкыбыз йолдызлары!


Вак-вак атлап, йомшак басып
Бии кызлар яланда.
Күбәләктәй әйләнәләр... –
Илһам иңә җаннарга!

Былбылларны таң калдыра
Дәртле-монлы җырлары...
Күз өстендәге каш кебек
Безнең якның кызлары!

Алматының алмасыдай
Безнең якның кызлары.
Нур чәчеп, балкып торалар
Халкыбыз йолдызлары!...

## НИКАХ ТУЕ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Догаларын укый, укый
Сакалын сыйпый, сыйпый,
Мулла бабай Никах укый,
Вәгазен сөйли, сөйли.

Никах туе, Никах туе –
Яшьләрнең изге туе.
Никах туе, бәхет туе,
Саф мәхәббәтнен туе.

Никах туе гомерлеккә
Чәчләрне-чәчкә бәйли,
Гашыйкларны бергә кушып –
Хисләрен бергә ялгый.

Нәселгә кер кундырмыйча,
Җылы оя корыгыз!
Башкаларга үрнәк булып,
Матур-тату торыгыз!..

Никах туе, Никах туе –
Яшьләрнең изге туе.
Никах туе, бәхет туе,
Онытылмас гомер буе!



# СӨННӘТ ТУЕ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Бай тарихлы милләтемнең
Гореф-гадәтләрен саклыйбыз.
Тап төшерми, егетләрчә
Изге бур(ы)чыбызны аклыйбыз.

Кушымта:
Сөннәт туе, сөннәт туе,
Йөзләрдә иман нуры...
Чын мөселман булды бүген –
Тагын бер татар улы.

Динебезгә, дөнебезгә,
Гомерлеккә тугры калабыз.
Нәселебез динле булган,
Без шулардан үрнәк алабыз.

Кушымта.

Фәрештәләр канат кагып,
Тели безгә изге теләкләр.
Бәхет теләп яшь буынга –
Ярсып тибә безнең йөрәкләр.

Кушымта:
Сөннәт туе, ирләр туе,
Йөзләрдә иман нуры!..
Чын мөселман булды бүген
Тагын бер татар улы.



# ШУЛ БӘХЕТ МИҢА ҖИТӘ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Кырыс язмыш аермаса,
Гомер юлын бергә атласак,
Яшьлек мәхәббәтебезне
Тап төшермиенчә сакласак –
Шул бәхет миңа җитә!

Кушымта:
Оныклар-онықчалар
Татар булып тусалар,
Татарча яшәсәләр –
Шул бәхет миңа җитә!..

Кызларыбыз, улларыбыз
Инсафлы булып үссә,
Хезмәт сөючән булып
Кыенлыкларга түзсә –
Шул бәхет миңа җитә!

Кушымта.


Мәхәббәт җимеше булып,
Оныклар туып торса,
Ата-бабалар нигезе
Җимерелмичә торса –
Шул бәхет миңа җитә!

Кушымта.

Оныклар-онықчалар,
Безнең юлны дәвам итсә,
Гомеребез озын булып,
Нәвәрәләр күреп үтсә,
Йөрәкләргә шифа биреп
Нәвәрәләр биттән үпсә –
Шул бәхет миңа җитә!..
Кушымта.

# АЛТЫН ТУЙ

**Равил Гөзәиров сүзләре**




Чәчебезгә корау төште.
Оныкларда үсеп җитте.
Шау-гөр килеп яшьлек үтте –
Көмеш туйда узып китте.

Кушымта:
Алтын туйлар котлы булсын,
Бокаллар мөлдер тулсыннар!
Алтын туйны туйлаучылар –
Гомерлеккә пар булсыннар!

Ике йөрәк кушылганга,
Ярты гасыр үтеп китте.
Яшьлек хисенә төренеп –
Алтын туйда килеп җитте.
Кушымта.

Ак болытларга атланып,
Гомер ага канатланып,
Узган гомер мизгел генә –
Узып китә бик тиз генә.
Кушымта.

Мәхәббәт ул серле чишмә,
Эчсәң суын исерәсең.
Яшьли сөю хисләреңне –
Исеңә гел төшерәсең.
Кушымта.



# ЯШӘҮ ҮЗЕ ГАЛӘМӘТ

**Равил Гөзәиров сүзләре**




Яшәү үзе бер галәмәт!
Дөньяда яшәү – хикмәт...
Кыска булганга – кадерле
Ходай биргән шул нигъмәт!

Кушымта:
Алтмыш, җитмеш, сиксәндә дә:
Картаймый күңел бердә.
Яшик дуслар шулай бергә –
Хафаланмыйча бердә.

Яшәү ялкыны сүнмәсен!
Туксанга җткәндә дә.
Мәхәббәткә тулы булсын –
Йөз яшькә килгәндә дә.


Кушымта.

Җырлап яшик әле, дуслар!
Җыр булса үлем кача.
Җырның тылсымлы көчләре –
Гомер ишеген ача.

Кушымта.

## АЛТЫН ТУЙ ВАЛЬСЕ

**Равил Гөзәиров сүзләре**



Алтын туйлар котлы булсын!
Күңелләр нурга тулсын!
Мәхәббәткә тулы булсын –
Эшләребез уң булсын!..

Кушымта:
Гашыйкларның йөрәкләре,
Яратам дип типсеннәр!
Кызарып пешкән иреннәр –
Берсен-берсе үпсеннәр!

Яшьлек язың кыска диләр,
Ошанмагыз бу сүзгә!
Һавадагы йолдызларда –
Бәхет телиләр сезгә!

Кушымта.

Алтын – туйлы, алтын көздә,
Алтын төстә агачлар
Уйнап-көлеп бәйрәм итик,
Өркеп качсын сагышлар.

Кушымта.



# “САРМАНЫМ”

## Рәвил Гөзәиров сүзләре



Сарманыбыз моң чишмәсе,
Җырлап-чылтырап ага.
Бар халыкның йөрәгенә
Сүнмәс утларын яга.

Кушымта:
Сарманым, Сарманым,
Мәңге яшә, Сарманым.
Сарманым, Сарманым,
Син бит минем арманым.

Күпмеләрнең йөрәгенә
Шифа булды моңнарың.
Ун еллыгын бәйрәм итеп,
Яңгырасын җырларың.

Кушымта.

Ун еллыгың бәйрәм итеп,
Яңгырасын җырларың.
Бар халыкнын йөрәгендә
Урын алсын моңнарың.

Кушымта.

Күңел хисләрем яңара,
Сарманым, сиңа килсәм.
Хыялларым канатлана,
Тик синең белән йөрсәм.

Кушымта.

# БЕЗНЕҢ “САРМАН”

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Ала-таудан Бала-тауга
Китә “Сарман” моңнары.
Бергә җырлап, бергә бию –
Шул “Сарманның” уйлары.

К у ш ы м т а:
Сайрат, сайрат гармуныңны,
Биесеннәр яшь кызлар.
Баскан җирдән ут чыгара
Безнең “Сарман” дисеннәр.

Ямьле Сарман буйларында
Сандугачлар сайрыйлар.
Матур кызлар уйларында,
Белмим, кемне сайлыйлар.

К у ш ы м т а.

Уйна, дустым, гармуныңны,
Биесен әле кызлар.
Йөрәкләрне җилкендерә
Безнең “Сарман” дисеннәр.

К у ш ы м т а.

Иркен казак даласында
Яңгырый “Сарман” җырлары.
Бергә җырлап, бергә бию –
Шул “Сарманның” уйлары.

К у ш ы м т а.

# ТӘҮГЕ СӨЮ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Агым сулар агар инде
Ярларына сыймыйча.
Яшь гомерләр узар инде
Чын йөрәктән сөймичә.


Төшләремдә күргән кебек
Яшьлегемнең хисләре.
Колагымда һаман чыңлый
Сөям дигән сүзләре.

Яшел үләннәр каплады
Балачак сукмакларын.
Тик йөрәгем иң түрендә
Сине генә саклады.

Шул сукмакларда калдылар
Ялан-аяк эзләрем.
Килер сыман ераклардан
Тәүге сөю хисләрем.

## САГЫНАМ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Сагынам туган якларның
Чишмәләрен, суларын.
Алсу таңнар аткан чакта
Сандугачлар сайравын.


Түбәночтан югарочка
Җырлашып үткәннәрне.
Озатканда сөйгәнемнең
Кочаклап үпкәннәрен.

Истә калган аулак өйләр,
Җырлаганда моңлы көйләр.
Гашыйкларның саф хисләре,
Чәчәкләрең хуш исләре.

Колагымда һаман чыңлый
Җиз кыңгырау чыңнары.
Яшьлегемә чакыралар
Тальян гармун моңнары.

# КАР СУЛАРЫ

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Эрегәндә ап-ак карлар,
Искә төшә Кызыл-ярлар.
Йөрәкләрдән китми һаман
Яшьлектәге сөйгән ярлар.


Кар суларына карасам,
Сызыла йөрәк майларым.
Берсен-берсе куган кебек
Үтә минем айларым.

Кар сулары алып китә
Безнең салган эзләрне.
Еллар аша сагындырып
Матур кара күзләрне.

Кар сулары ташкын булып
Аксын туган илләргә.
Калган эзләрне югалтмый
Туып үскән җирләргә.

## КИЛСЕННӘР МАТУР ЯЗЛАР

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**





Бөтен дөньяны яшәртеп
Килде тагын матур язлар.
Һавалардан тезелешеп
Каңгылдашып киткән казлар.

Уяндылар урман-кырлар,
Калын карлар эреп акты.
Ямьләндереп тирә-якны
Умырзая чәчәк атты.

Бүләк итик сөйгәннәргә
Беренче гөл бәйләмнәрен.
Уйнап-көлеп каршы алыйк
Җиңү, хезмәт бәйрәмнәрен.

## ИРТӘНГЕ ТАҢ НУРЫНДА

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Иртәнге таң нурларында
Барлык дөнья уянды.
Алсу таңнар атуына
Гөлчәчәкләр куанды.


Моңлы итеп сандугачлар
Ярсып-ярсып сайрады,
Талдан-талга кунып, сайрап
Пар булганын сайлады.

Чык тамчылары җемелди
Якты кояш нурында.
Гөлнур килә басу буйлап,
Гөл бәйләме кулында.

Без дә шулай бергәләшеп
Алга атласак иде.
Пар сандугач кебек сайрап
Гомер уздырсак иде!

# ӘНКӘЙЛӘР

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Син бәхетле әле, дустым,
Язмыш сине ятим итмәгән.
Авырлыклар күргәндә дә
Яннарыңнан әнкәң китмәгән.


Изгеләрдән изге булып,
Безнең өчен яши әнкәйләр.
Әлдә булса безне уйлап,
Күз яшьләрен түгә әнкәйләр.

Гөлбану әнкәбез шулай,
Җил-давылдан безне саклады.
Тормыш баскычыннан алга,
Сиксән берен бүген атлады.

Әнкәйләргә без телибез
Теләкләрнең шундый олысын.
Тәбрик итеп, гел хөрмәтлик,
Җәлләмичә йөрәк җылысын.

## ЯҢА ЕЛ КОТЛЫ БУЛСЫН

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**



Тәрәзәгә гөлләр салып
Тагын килде яңа ел.
Яшен, картын куандырган,
Котлы булсын яңа ел.

Кушымта:
Ыгы-зыгы көннәр белән
Узган ел узып китте.
Сәгать уникене сукты –
Яңа ел килеп җитте.

Халкыбыздай киң күңелле
Шундый юмарт яңа ел.
Җәлләмичә кар буранын
Шаулап килде яңа ел.


Кушымта.

Барыбызның күңелендә
Урын алган яңа ел.
Тау башыннан чана шуып
Эзләр салган яңа ел.

Кушымта.

# ТУГАН КӨН

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**




Ай тулганда, тугансың,
Шуңа нурлы йөзләрең.
Татар булып туганга –
Шундый матур сүзләрең.

Кушымта:
Әй туган көн, туган көн!
Дуслар килә торган көн.
Бәллүр бокаллар тотып –
Күңел ача торган көн!

Туган көндә, уен-көлке;
Кояштай балкый йөзләр.
Көне-төне гөрләшеп –
Бетәрлек түгел сүзләр.

К у ш ы м т а:
Әй туган көн, туган көн!
Дуслар килә торган көн.
Бәллүр бокаллар тотып –
Бүләк бирә торган көн!

Ходай биргән, туган көн,
Һәркемнең үзенеке.
Уйнап-көлеп, күңел ач.
Бүгенге көн синеке!

К у ш ы м т а:
Әй туган көн, туган көн!
Дуслар килә торган көн.
Изге теләкләр, теләп –
Бәйрәм итә торган көн!

# ЯЗ БӘЙРӘМЕ «САБАНТУЙ”

**Рәвил Гөзәиров сүзләре**





Сабантуйлар җитсә, канатланам.
Моңлы җырлар җырлап моңланам.
Милләтемнең киләчәген уйлап –
Чабыш атларына атланам.

“Сабан туе” үзе бер могҗиза,
Сабан туе – татар канында!
Сабан туе – татарныкы булыр,
Мактанырлык халкы барында!

Болгар бабаларым, сабан туен,
Изге мирас итеп калдырган.
Сабан туе – татарныкы диеп,
Тарих битләренә яздырган.

## ШАРЫК КЫЗЫНА

**Рәвиль Гөзәиров сүзләре**




Хиялдагы бер сылу,
Әйтерсеңдә дәрештә.
Ару-Талуны белми –
Элгер-җитез, һәр эштә.

К у ш ы м т а :

Әй Гөлнара, Гөлнара
Йөрәгемнең сагышы,
Әй Гөлнара, Гөлнара
Гомеремнең агымы.

Тангы бирми иртә кич,
Биләдең уйларымны,
Серле күз карамларың
Яулады йөрәгемне.

К у ш ы м т а :

Гөл-чәчәкләргә күмелчәк,
Кызлар йөргән еу юкы.
Әй гөлнара, Гөлнара –
Сагындыруын бу юлы.


Яшьлегемнең дәһонен,
Бәхетем син Гөльнара!
Яшәү көче бирәсең –
Бәхетем син Гөльнара.

К у ш ы м т а :

Гөл-чәчәкләргә күмелчәк,
Кызлар йөргән еу юкы.
Әй гөлнара, Гөлнара –
Сагындыруын бу юлы.

# ӘЙ СТӘРЛЕ, СТӘРЛЕ!

**Рәвиль Гөзәиров сүзләре**




Онта алмыйм, һәр чак истә,
Стәрлебаш яклары...
Әй стәрле, стәрле –
Чайханалы стәрле.

Кушымта:
Әй стәрле, стәрле
Салкын сулы, чишмәле.
Әй стәрле, стәрле
Халкын синең хәстәрле.

Стәрлебаш урманлы як.
Ямъле аның кырлары!
Йөрәкләрне җилкендерә –
Моңлы дәртле җырлары.

Кушымта.

Яланнарың иркен алан,
Тугайга пешә балан.
Еракларадан сиңа кайтам –
Мин дә бит синең балаң.

Кушымта.



# И ТУГАН ТЕЛ

**(Габдулла Тукайга ияреп)**

**Тимер Заһит сүзләре**




И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле.
Телемдәй газиз халкым бар,
Сөекле туган илем.

И туган тел, мөкатдәс тел,
И моңлы татар теле.
Татар теле исән әле,
Шуңа халкым да тере.

И туган тел, синең белән
Гомерем үтсен шулай.
Татар телен мәңгелеккә
Бер үзең сакла, Ходай!

# САНДУГАЧЫМ, БЫЛБЫЛЫМ

**Тимер Заһит сүзләре**




Сандугачым, былбылым,
Мин берүзем, ялгызым.
Күңелемдә син генә,
Күктә тик бер йолдызым.

Сандугачым болында
Сулар эчә чыклардан.
Үзәкләрем өзелә
Искә төшкән чакларда.

Сандугачым, гүзәлем,
Канатларын кагына.
Ай артыннан ел үтә,
Һаман сине сагынам.

Сандугачым, урманда
Син кунасың кайларга?
Бәхет бит ул, сөйгәндә
Парлап бергә сайрарга.

# ЯЗЛАР ҖИТКӘЧ

## Тимер Заһит сүзләре



Язлар җиткәч, күлмәк кигән актан
Каен яшел алка таккан.
Киек казлар очып кайткан.
Тугаен сагынып,
Канатын кагынып,
Кайтыр өчен ашкынган ул,
Туган якка талпынган ул
Гөлләр үскән, язлар җиткән чакта.

Язлар җиткәч, кояш нурын сибә
Йөрәк ярсып-ярсып тибә.
Ачы сагыш үзәк өзә.
Син генә сагынып,
Син генә ашкынып,
Минем янга кайтмыйсың да,
Бәлки искә алмыйсың да,
Мескен йөрәк шуңа ничек түзә?

Язлар җиткәч, сине көтәм һаман,
Хисләр мәңге сүнмәс сыман,
Эчем гел ут, дөрләп янам.
Син минем бер генәм,
Иң назлы гөл генәм,
Сине генә юксынам мин,
Өзелеп-өзелеп сагынам мин,
Сөйгән ярым, янган утта калам.

# И ТУКАЙ

**Тимер Заһит сүзләре**




Бәхет өчен бу җиһанга
Килгән булса да бала,
Язмыш аны читкә кагып
Михнәт утына сала.

Кушымта:
И Тукай, моңлы Тукай,
Кайгылы, зарлы Тукай.

Чыдам була, тырыш була,
Үсеп җитә бу егет,
Идел суы, Урал суы
Бергә көч биргән кебек.

К у ш ы м т а:
И Тукай, нурлы Тукай,
Югалмас җырлы Тукай.

Якты дөнья читлеге тар
Ятим үскән шагыйрьгә.
Сазы сынды, үзе сүнде,
Сагыш салып бәгырьгә.

К у ш ы м т а:
И Тукай, нәүмиз Тукай,
Халкына газиз Тукай.

Күктән йолдыз атылгандай,
Очты ялтырап Тукай.
Ядкарь итеп Тукай моңын
Җырлый һавада тургай.

К у ш ы м т а:
И Тукай, бөек Тукай,
Син исән кебек, Тукай!

# ЧИТ ИЛЛӘРДӘ ТАТАР
## (Кытай Армиясы генералы, милләттәшем Маргуб Исхаков истәлегенә)

### Тимер Заһит сүзләре



И татарым, кая гына сине
Чәчеп таратмаган язмышлар?
Күп татарга насыйп булган икән
Чит җилләрдә гомер агышлар.

Кушымта:
Кытай илендәге генерал да –
Милләтемнең газиз баласы.
Шушы илнең азатлыгын яклап,
Канын түккән, алган ярасын.

Кайда торса, шунда татар үзен
Тырыш, эшчән итеп таныткан.
Игенен дә иккән, сәүдә иткән,
Кыюлыгы белән дан тоткан.

Кушымта.


Мөгаллим дә булган шунда татар,
Мәктәп ачкан, белем тараткан.
Хезмәткәр дә булган ул, галим дә,
Оста булгандыр һәр тарафтан.

Кушымта.



# СУ СОРЫЙЛАР ГӨЛЛӘР

**Тимер Заһит сүзләре**




Су сорыйлар гөлләр, су сорыйлар,
Ал гөлләрем суга сусаган.
Су сипмәгән алсу гөлләр сыман
Мин сулыгам инде ни заман.


Су сорыйлар гөлләр, су сорыйлар,
Юк аларга сулар сибүче.
Мин дә шул сусаган гөл хәлендә,
Юк юатып миңа килүче.

Су сорыйлар гөлләр, су сорыйлар,
Ник кызганмый икән берәү дә?
Сулган гөлдәй көн дә яна йөрәк,
Тик әйталмыйм аны берәүгә.

Су сорыйлар гөлләр, су сорыйлар,
Су сипмәсән, гөлләр шиңәдер.
Син еракта инде, синсез гомер
Бер сулган гөл кебек нигәдер.

## СЫНДЫРДЫҢ КАНАТЫМНЫ

**Тимер Заһит сүзләре**



Кыска булды синең еллар,
Читләргә тараттыңмы?
Сындырдың бит,
Сындырдың бит
Син, балам, канатымны.

Назлауларым аз булдымы,
Әллә аз яраттыммы?
Ник сындырдың,
Ник сындырдың
Син, балам, канатымны.


Туктаттың бит кинәт кенә
Ашкан пар атымны.
Сындырдың шул,
Сындырдың шул
Син, балам, канатымны.

Күңелләрем дә кара хәзер,
Кайгылы җаным, моңлы.
Ник сындырдың,
Ник сындырдың
Син, балам, канатымны.



# БАЛА СӨЕНЕЧЕ

**Сания Галиева сүзләре**





Бәхет, шатлык бергәләшеп килсә,
Ана сөенә, ана куана.
Яулык кырыеның очы белән
Күз яшьләрен сөртә бит ана.

Күңел кылларыңны тибрәндереп,
Шатлык, сөенеч китерсә бала,
Ана күңеле ниләр кичергәнен
Күктә белә бары бер Алла.

Бу куаныч күкрәгенә сыеп,
Дулкынлана ана йөрәге.
Бәхет мизгелләре күбрәк булсын,
Бу ананың изге теләге.

# ЯЗ ҖИТТЕ

**Сания Галиева сүзләре**




Яз җитте, табигать җанланды,
Һәр бөҗәк, һәр җанвар куанды.
Тирбәтте күңелне яз моңы,
Күңелдә мәхәббәт уянды.

Җырлады күңел, кыллар талпынды,
Саф чишмә күк моңнар агылды.
Тик синең дәшмәвең борчыды,
Яз җитте, күңелгә кагылды.

# МАТУР БУЛСЫН КИЛӘЧӘК

**Рөстәм Әбдусәләмов сүзләре**



Бакчаларга мин кердем,
Матур чәчәкләр күрдем.

Кушымта:
Кызыл чәчәк, ал чәчәк
Матур безнең киләчәк.

Кояш нурларын чәчә,
Бәхет капкасын ача.

Кушымта.

Биибез бергәләшеп,
Җырлыек без гөрләшеп.

Кушымта.



# КҮБӘЛӘК

**Майсәрвәр Шәйдуллина сүзләре**




Гөлдән гөлгә очып куна
Зәңгәр чобар күбәләк.
Ләп-ләп, ләп-пәп,
Зәңгәр чобар күбәләк.

Кулым суздым тотам диеп,
Очты, очты күбәләк.
Ләп-ләп, ләп-ләп,
Очты, очты күбәләк!

Күтәрелде өскәрәк –
Китте мәллә үпкәләп!
Ләп-ләп, ләп-ләп,
Китте мәллә үпкәләп.

Очып килә күбәләк,
"Тимим, уйныйк бергәләп".
Ләп-ләп, ләп-ләп,
"Тимим, уйныйк бергәләп".

# ИШЕЛ БУЕ – БЕЗНЕҢ ЯК

**Ришат Шакиров сүзләре**




Туган ягым Урал буйларында,
Агыйделдә үтте яшьлегем.
Тик шулай да саклыйм уйларымда
Ишел ярларының ташкынын.

К у ш ы м т а:

Кызыл гөлләр үскән борма сукмакларың
Яшьлегемә килеп бәйләнде.
Сусаганда эчкән саф суларың
Чишмә суларына әйләнде.

Синдә үткән якты көннәремдә
Җәйләүләрдә җырлар җырладым.
Ишел буйларының гөлләреннән
Иң матурын сиңа җыйнадым.

К у ш ы м т а.

Мин бу җирдә гүзәл дуслар таптым,
Күңелләре һәрчак нинди ак.
Мин бу җирдә гөрләп чәчәк аттым,
Ишел буе – безнең туган як.

К у ш ы м т а.

# ВОЛШЕБНЫЙ АЛАТАУ

## Слова М. Альтаева



Мы друзьям всегда рады, это не слова
Санаторий «Алатау» полон волшебства.
Кто хоть раз в санатории нашем отдыхал,
Тот энергию гор полон в себя вобрал.

Припев:
Здесь у нас чистый воздух и горная вода!
Санаторий окружают горы и леса!
Чтоб эту красоту, вы смогли познать,
«Алатау» с любовью вас всегда готов встречать!

В «Алатау» так прекрасно, чудный персонал
И у нас каждый в деле большой профессионал.
Мы детишкам поможем силы обрести
С твердым шагом по жизни им ещё идти.

Припев.

# ОСЕНЬ

## Слова А. Плещеева




Осень наступила,
Высохли цветы,
И глядят уныло
Голые кусты.

Припев:
Зашумели воды
Быстрого ручья,
Птички улетели
В теплые края.

Вянет и желтеет
Травка на лугах,
Только зеленеет
Озимь на полях.

Припев.

Туча небо кроет,
Солнце не блестит,
Ветер в поле воет,
Дождик моросит.

Припев.



# ПРОЩАЙТЕ, ЛАГЕРЯ!

**Слова О. Бедаревой**




Зелёная аллейка,
Песчаная линейка.
Сегодня в час рассвета
Построился отряд
И с песенкой походной
Уходим мы сегодня.
До будущего лета
Прощайте, лагеря!

Припев:
Прощайте, не скучайте
И снова нас встречайте.
До будущего лета,
Прощайте, лагеря!

Желтеет луг зеленый,
Грустят большие клены,
В цвет осени одеты
Зарделись, как заря.
Мы здесь чудесно жили,
Мы с песенкой дружили.
Теперь нас школа встретит
В день первый сентября.

Припев.

Лети, напев веселый,
Идут ребята в школу!
До будущего лета
Прощайте, лагеря!
Прощайте, не скучайте
И снова нас встречайте.
До будущего лета,
Прощайте, лагеря!

Припев.

# СПОРТИВНЫЙ МАРШ

**Слова А. Соловьева**




В спортивный зал и в санатории
Нам с этой песней по пути,
Чтоб одолеть недуги вскоре
И на вершины гор взойти.

Припев:

Физкульт-ура, физкульт-ура
Поём мы с самого утра.
Физкульт-ура, физкульт-ура,
Нам встать спортсменами пора.

Тот, кто зарядке цену знает,
Кто смелостью и силой горд,
Тот вместе с нами повторяет,
Что со здоровьем дружит спорт.

Припев.


Здесь в Алатау «ели» царство
Поможет свежий воздух нам.
Ведь, лучше всякого лекарства,
Его целительный бальзам!

Припев.



# ВЕЛИЧАВАЯ МАСЛЕНИЦА

**Слова Галимжана Тамендарова**




Едет по полю родная,
Масленица золотая.
Кони только вороные,
Сани только расписные.

Припев:
Масленица, масленица
Наша ты красавица.
Масленица, масленица
Очень ты нам нравишься

Масленица годовая,
Она гостья дорогая.
Пешая она не ходит,
На лошадке всех разводит.

П р и п е в.

Ей, вы кони удалые
Слуги тоже молодые.
Масленица к нам пришла,
Блины на праздник напекла.

П р и п е в.

# ВСТРЕЧА ЗИМЫ

**Слова Галимжана Тамендарова**




Ой ты зимушка-зима
Зимушка морозная.
Как и раньше в старину
Вновь встречаем мы зиму.

Вот крещенские морозы
Вьюга снег, кругом сугробы.
Снег за окнами скрепит,
Сидеть дома не велит.

Веселей гармонь играй
Всех на праздник приглашай.
Будут пляски и частушки,
И румяные ватрушки.

Ой ты зимушка-зима
Зимушка морозная.
Выходи народ плясать
Нашу зимушку встречать.

# ДИН-ДОН

## Слова Галимжана Тамендарова



Под горою у реки
Живут гномы-старики
Колокольчики звенят
Танцевать зовут ребята.

П р и п е в:
Дин-дон, дин-дон
Слышим мы капели звон
Дин-дон, дин-дон
Пляшут люди под гармонь.

Масленицу мы зовем
Громко песню все поём
Свети солнышко свети
И весну скорей зови.

П р и п е в.

Р е ч и т а т и в:
Гори-гори ясно,
Что бы не погасло
Гори-гори ясно
Весну встретим славно
Гори-гори ясно,
Что бы не погасло
Гори-гори жарко
Весну встретим сладко.

# СПОРТИВНЫЙ МАРШ

**Слова А. Соловьева**




В спортивный зал и в санатории
Нам с этой песней по пути,
Чтоб одолеть недуги вскоре
И на вершины гор взойти.

Припев:
Физкульт-ура, физкульт-ура
Поём мы с самого утра.
Физкульт-ура, физкульт-ура,
Нам встать спортсменами пора.

Тот, кто зарядке цену знает,
Кто смелостью и силой горд,
Тот вместе с нами повторяет,
Что со здоровьем дружит спорт.

Припев.


Здесь в Алатау «ели» царство
Поможет свежий воздух нам.
Ведь, лучше всякого лекарства,
Его целительный бальзам!

Припев.



# СҮЙІКТІ БІЗДІҢ АСТАНА

**Өлеңін жазған Мұзафар Әлімбай**




Қанат жайып Есілден,
Кең даладай көсілген.
Жасампаздың нұрындай
Жақсылықтың нұрындай.

Қайырмасы:
Салтанаттың сәніндей,
Сүйікті біздің Астана!
Махаббаттың әніндей
Сүйікті біздің Астана!

Сұлулықтың көркіндей,
Хас батырдың сертіндей.
Жастық шақтың өзіндей,
Шаттық думан көзіндей.

Қайырмасы.

Жарқыраған самала,
Сәуле құяр санаға.
Атаға да балаға
Игілікті заманға.

Қайырмасы.



# ӘНІҢІ АЛТЫ ҚЫРДАН ӘН ҚОСАМЫН

## Өлеңін жазған Мұзафар Әлімбай



Ақ жарқын, Ай маңдайлы, шадыман жүз,
Тәтті алма өсіретін бағыбан қыз!
Бақшаңда таңменен ән шырқасаң,
Ертең де сазды әніңді сағынармыз.

Қайырмасы:
Сенбісің жан қосарым, жан қосарым?
Әніңе алты қырдан ән қосамын.
Тағдырдың қолдауымен, қолдауымен
Қай күні деймін сені жар-қосағым!?

Қайырмасы.

Еліткен үздігемін дауысыңа,
Естілсе, елеңдеймін жан ұшыра.
Жеңгетай жер-жаһанда бар масірә
Әніңдей ынтықтырған қауышуға.

Қайырмасы.

Басынан қос қырқаның тартып көше,
Әніміз жарасады шалқып, есе.
Қосылса салған әндей қуаттанып,
Құлшынар қыз бен жігіт «Халқым!» десе.

Қайырмасы.

# САҒЫНДЫРҒАН ЕРКЕТАЙЫМ

**Өлеңін жазған Серік Тұрғынбеков**




Алатаудың ар жағы –
Балықты көлдер арналы.
Сағындырған Еркетайым,
Жүрмін саған, "ей", барғалы.

Алатаудың бер жағы –
Ұзынағаш пен Қарғалы.
Сағындырған Еркетайым,
Көзің неге, "ей", салмадың?

Алатаудың жан-жағы –
Бақша-баулар алмалы.
Қайнарынан нәр ішсем де,
Көңіл шіркін, "ей", қанбады.

# ЭЧТӘЛЕК

**Ашкынам мин туган ягыма** ........ **5**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Истамбул** ........ **7**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Үлемсезлек** ........ **9**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Туй җыры** ........ **10**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Тамашачы дусларыма** ........ **12**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Син бит минем бер генәм** ........ **14**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Бер яшьлектә, бер картлыкта** ........ **15**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Җилләр исә** ........ **16**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Накия** ........ **17**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Котлы булсын сабантуй** ........ **19**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Безгә килде Кыш бабай** ........ **21**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Нурия** ........ **22**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Әй, гармун телләре** ........ **24**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Яшьлегемнең таңнары** ........ **26**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Салкын чишмә** ........ **28**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Җиңү көне** ........ **30**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Мамлютем кырларында** ........ **32**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Чабата** ........ **33**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Наурыз** ........ **35**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Әткәем** ........ **36**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Ә канатсыз миңа нишләргә?** ........ **38**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Безнең Тукай** ........ **39**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Әй сылу кыз, сылу кыз** ........ **40**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Кода белән кодагый** ........ **41**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Яр, яр!** ........ **43**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Ана телэге** ........ **45**

Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Безнең якның кызлары... 46**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Никах туе 47**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Сөннәт туе 49**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Шул бәхет миңа җитә 51**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Алтын туй 53**
Равил Гөзәиров сүзләре
**Яшәү үзе галәмәт 55**
Равил Гөзәиров сүзләре
**Алтын туй вальсе 56**
Равил Гөзәиров сүзләре
**“Сарманым” 58**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Безнең “Сарман” 60**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Тәүге сөю 62**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Сагынам 63**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Кар сулары 65**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Килсеннәр матур язлар 66**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Иртәнге таң нурында 67**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Әнкәйләр 69**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Яңа ел котлы булсын 70**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Туган көн 72**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Яз бәйрәме «Сабантуй” 74**
Рәвил Гөзәиров сүзләре
**Шарык кызына 75**
Рәвиль Гөзәиров сүзләре
**Әй стәрле, стәрле! 77**
Рәвиль Гөзәиров сүзләре
**И туган тел 79**
Тимер Заһит сүзләре
**Сандугачым, былбылым 80**
Тимер Заһит сүзләре
**Язлар җиткәч 81**
Тимер Заһит сүзләре
**И Тукай 83**
Тимер Заһит сүзләре
**Чит илләрдә татар 85**
Тимер Заһит сүзләре
**Су сорыйлар гөлләр 87**
Тимер Заһит сүзләре

**Сындырдың канатымны** ........................................................................................................ **88**
Тимер Заһит сүзләре
**Бала сөенече** ........................................................................................................ **90**
Сания Галиева сүзләре
**Яз җитте** ........................................................................................................ **91**
Сания Галиева сүзләре
**Матур булсын киләчәк** ........................................................................................................ **92**
Рөстәм Әбдусәләмов сүзләре
**Күбәләк** ........................................................................................................ **94**
Майсәрвәр Шәйдуллина сүзләре
**Ишел буе – безнең як** ........................................................................................................ **95**
Ришат Шакиров сүзләре
**Волшебный алатау** ........................................................................................................ **97**
Слова М. Альтаева
**Осень** ........................................................................................................ **99**
Слова А. Плещеева
**Прощайте, лагеря!** ........................................................................................................ **101**
Слова О. Бедаревой
**Спортивный марш** ........................................................................................................ **103**
Слова А. Соловьева
**Величавая масленица** ........................................................................................................ **105**
Слова Галимжана Тамендарова
**Встреча зимы** ........................................................................................................ **107**
Слова Галимжана Тамендарова
**Дин-дон** ........................................................................................................ **109**
Слова Галимжана Тамендарова
**Спортивный марш** ........................................................................................................ **111**
Слова А. Соловьева
**Сүйікті біздің Астана** ........................................................................................................ **113**
Өлеңін жазған Мұзафар Әлімбай
**Әніңі алты қырдан ән қосамын** ........................................................................................................ **115**
Өлеңін жазған Мұзафар Әлімбай
**Сағындырған Еркетайым** ........................................................................................................ **117**
Өлеңін жазған Серік Тұрғынбеков

Компьютерный набор текста и нот выполнил
Асхат Нигматуллин
----------
8-777-286-76-45 (мобильный)
E-mail: N_Askhat_R@mail.ru
Дата распечатки 09.12.2019 13:56:07